

«Заманча мәктәп: киләчәккә бер адым» милли проекты кысаларында ТР ЕМР «Иске Юраш урта мәктәбе» базасында 2021 елның 30 августында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм техник профильле мәгариф үзәген ачу тантанасы булды.

Үзәк ачылышында «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесе Теретьева Елена Дмитриевна, Иске Юраш һәм Илмәт авыл җирлекләре башлыклары Юнысов Р.Г. һәм Мингалеева Р. Т. , мәктәп хезмәткәрләре, ата-аналар һәм укучылар катнашты. Чакырылган кунаклар барлык катнашучыларны истәлекле вакыйга белән котладылар. Укучыларга фән өлкәсендә әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешүләрен һәм мәктәпнең барлык коллективына иҗади уңышлар теләделәр.

Мәктәп директоры Фәймә Тимербаева үз чыгышында «Үсеш ноктасы» үзәге гомумкультура кыйммәтләрен, санлы грамоталылыкны, проект эшчәнлеген, балаларның, педагогларның, ата-аналар җәмәгатьчелегенең иҗади социаль тормышка ашырылуын үстерү өчен мөһим һәм мәктәп укучыларында заманча компетенцияләр һәм күнекмәләр формалаштыруны тәэмин итәргә тиеш, дип билгеләп үтте. Үзәктә «Физика», «Химия», «Биология» фәннәре буенча яңартылган матди-техник база булган гомуми белем бирү программаларын гына түгел, ә IT-технологияләр, проект һәм дәрестән тыш эшчәнлек буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру планлаштырыла. Шушы программаларны тормышка ашыру максатыннан, кабинетлар бик күп җиһазлар белән тулыландырылды. Блок программалаштыруны үзләштерү өчен белем бирү конструктор датчиклары белән, мәктәп укучылары өчен цифрлы лаборатория (2 комп.), МФУ HP Lazer MFP 137 fnw, химик реактивлар комплекты, механика, мехатроника һәм робототехника буенча белем бирү җыелмасы, ноутбук (2), демонстрацион гербарияләр комплекты, демонстрацион коллекцияләр комплекты (биология курсының төрле темалары буенча), демонстрацион дымлы препаратлар комплекты (биология, лаборатор эшләр һәм уку тәҗрибәсе өчен җиһазлар җыелмасы (ОГЭ өчен комплектлар базасында), физика һәм химия фәннәре буенча лаборатор һәм демонстрацион тәҗрибәләр өчен приборлар.

Бәхәссез факт, “Үсеш ноктасы”ның өстенлекләре күп. Шушы мөмкинлекләрне кулланып укучыларның дәресләрен генә түгел, дәрестән тыш эшчәнлекләрен дә эчтәлекле итеп оештыру укытучылардан тора. Балалар тәҗрибәле педагоглар җитәкчелегендә укырлар һәм заман белән бергә технологик һәм заманча үсеш алырлар, дип ышанасы килә.

**Фәймә Тимербаевна**



Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан 12 илкүләм милли проект игълан ителгән иде. Милли проектларның төп бурычы - һәр Россия гражданины һәм һәр гаилә тормышында реаль уңай үзгәрешләр булдыру. Алабуга районы да күп кенә федераль проектларда катнаша.

«Заманча мәктәп: киләчәккә бер адым» милли проекты кысаларында ТР ЕМР «Иске Юраш урта мәктәбе» базасында 2021 елның 30 августында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм техник профильле мәгариф үзәген ачу тантанасы булды.

Аның максаты – шәһәр һәм авыл мәктәпләренең техник базалары, заманча мөмкинлекләре аермасын киметү.Үзәкнең төп бурычы: биология, физика, химия фәннәрен укыту методларының эчтәлеген яңарту һәм камилләштерү; халыкның гомум-мәдәни компетенцияләрен һәм белемнәрен, проект эшчәнлеген, балаларның, педагогларның һәм ата-аналарның иҗади мөмкинлекләрен үстерү өчен дәрестән тыш чорда инфраструктураны куллану.

Әлеге проектны алга таба тормышка ашыру максатынна ике педагог – Хөсәенова Гөлчәчәк Равил кызы, Саляхетдинова Фәимә Тимербай кызы Татарстан Республикасының «Үсеш ноктасы» үзәкләренең белем бирү сессиясендә курслар уздылар.

Без, Иске Юраш мөгаллимнәре коллективы, бу проектта катнашуыбызны дөрес гамәл, дөрес адым дип уйлыйбыз, чөнки укучылар, кайда яшәүләренә карамастан, бүгенге көн таләпләренә яраклы сыйфатлы белем алырга, киләчәккә тигез мөмкинлекләр белән атларга хокуклы.

Бәхәссез факт, “Үсеш ноктасы”ның өстенлекләре күп. Шушы мөмкинлекләрне кулланып, без, укытучылар, укучыларның дәресләрен генә түгел, дәрестән тыш эшчәнлекләрен дә эчтәлекле итеп оештырырбыз дип уйлыйбыз.

**Клара Гайнетдинова**



«Үсеш ноктасы» үзәге мәктәп укучыларында мәдәни үзкыйммәтләрне, уку-укыту заманча алымнары куллану белемен, проектлар эшләүдә, шулай ук педагоглар, ата-аналар арасында иҗади һәм социаль тормышка үз урыныңны үстерүдә мөһим урын алып тора. Ул мәктәп укучыларында заманча компетенцияләрне һәм күнекмәләрне формалаштыруны тәэмин итәргә тиеш. Үзәктә биология, физика, химия фәннәре генә түгел, ә IT-технологияләр, медиатехнологияләр, шахмат, проект һәм дәрестән тыш эшчәнлек буенча өстәмә белем бирү программалары да тормышка ашырыла.

Үзәк өч кабинеттан тора, бүгенге көндә аларның һәркайсы мәктәп һәм сыйныфтан тыш эш өчен җиһазландырылган. Кабинетлар укучылар һәм педагоглар өчен заманча приборлар һәм инструментлар: квадрокоптерлар, беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча мастер-класслар өчен манекеннар, ноутбуклар белән җиһазландырылган.

Мондый үзәк ярдәмендә әлеге мәктәп укучылары, яңа мөмкинлекләр ачып, төрле яклап үсеш ала башлады. «Үсеш ноктасы» үзәгенең эше мәктәп укучылары өчен сыйфатлы заманча белем бирү мөмкинлекләрен киңәйтә, балаларда заманча технологик һәм гуманитар күнекмәләр булдырырга ярдәм итә.

**Лилия Юнысова**



21нче гасыр тормышның барлык өлкәләренә үзгәрешләр алып килде. Без, укучыларга, укуы кызыклы булсын өчен, мәктәп базасында “Үсеш ноктасы” мәгариф үзәге ачылды. Үзәк “Биология”,“Физика”, “Химия” фәннәрен үз эченә ала. Бу фәннәрне укыту кабинетлары тулысынча ремонтланды, яңача җиһазландырылды. Бу, әлбәттә, безнең остазларыбызга яңа ысуллардан файдалануны тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк. Мәктәбебездә бу процесс инде яна уку елыннан ук башланып китте дип әйтергә кирәк. Дәрес вакытында гына түгел, дәрестән тыш вакытта, түгәрәкләрдә өстәмә гомумбелем бирү программалары белән шөгыльләнә башладык. Башлыча, проект эшчәнлеге алып

барыла.Үзәкнең матди-техник базасы проект эшчәнлегенә менә дигән мәйданчык булыр, дип уйлыйбыз.

Укытучы апаларыбыз белән яңадан –яңа идеяләр белән янып яшәү безне китап, компьютер белән тагын да ныграк дуслаштырды. Алга таба үсеш һәм белем сыйфатын арттыру өчен, без алдагы тормышыбызда тагын да катлаулырак бурычлар куярга, әйләнә-тирәне үзгәртергә, уңайлы торыштан чыгарга, диван белән кәнәфидән аерылырга һәм яшәешебездә нәрсәне дә булса үзгәртү дәрәҗәсенә күтәрелербез дип ышанасы килә. Кешенең үсеш ноктасы шушы мизгелдән башлана да инде. Үсеш ноктасы – үзгәрешләребез өлкәсе, үсешебез таянычы ул. Үзәгебездә яңа белемнәр алырга омтылып, үзгәрергә һәм дөньяны яхшы якка үзгәртергә теләүче яшь, креатив, мавыгучан, яңа идеяләр һәм теләкләргә бай балалар булырбыз дип ышандырасы килә.

**Азалия Мирхайдарова**